РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АГЕРЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул. Г.Ахметовой, д.14а, с. Агерзе,
423305

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ӘГЕРҖЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Г.Ахметова ур., 14 А нче йорт, Әгерҗе
авылы, 423305

Тел./факс(885592)44-5-21; E-mail: Ager.Azn@tatar.ru: https://aznakayevo.tatarstan.ru/agerzinskoe-selskoe-poselenie.htm

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«21» октябрь 2022 ел № 31

2021 елның 14 декабрендәге 24 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслау турында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә өстәмәләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 1601 статьясындагы 32 пунктының өченче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. 2021 елның 14 декабрендәге 24 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслау турында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесе» 292 бүлекне түбәндәге эчтәлекле юллар белән тулыландырырыга:

| | | |
|---|---|---|
| 292 | 2 02 25576 10 0000 150 | Авыл территорияләрен комплекслы үстерүне тәэмин итүгә авыл җирлекләре бюджетларына субсидияләр |
| 292 | 2 02 29999 10 0000 150 | Авыл җирлекләре бюджетларына башка субсидияләр |
| 292 | 208 10000 10 0000 150 | Түләүләр башкару өчен авыл җирлекләре бюджетларыннан (авыл җирлекләре бюджетларына) акча күчерү |

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 1 августыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Азнакай муниципаль районы сайтында (http://aznakayevo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Н.Н.Хәсәнов